СӘЙ ГОМЕРНЕ, СӘЙ ХАЛЫКНЫ, СӘЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӘНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

5 апрель, 1997 ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 38 (8050) | Бәясе билгеләнгәнчә

Яңа оешмада тәртип тә яңача

Ел башында «Норлатгаз» эксплуатация - производство идарәсе оештырылуы турында хәбәр иткән идек инде. Бүген ул - беренчел бурычы халык ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән гыйбарәт булган мөстәкыйль хуҗалык берәмлеге. Яңа оешманың мөмкинлекләре зур булган кебек, бурычлары да яңа. Һәм шулай ук проблемалары да. ЭПУ начальнигы В.В.БОГАТИКОВ белән без әнә шулар турында сөйләштек.

- Владимир Васильевич, яңа оешма төзелү гадәттә структур үзгәрешләргә дә китерә. Аларыннан сез дә котыла алмагансыздыр?

- Яңа оешма төзелү һич тә үзмаксат түгел иде, объектив зарурлыктан килеп чыкты. Коллектив алдына куелган бурычларның даирәсе киңәйгәнгә күрә без берничә махсус лашкан служба төзедек. Алар арасында авария - диспетчерлык службасы, комплекслы служба, газ режимы бүлеге, техник күзәтчелек службасы бар. Кулланучыларга газдан файдалану өчен түләүгә контроллекне газ режимы бүлеге алып баруын, ә газ өчен түләү мәсьәләләре буенча бухгалтериягә мөрәҗәгать итәргә киреклеген белү мәслихәт.

- Соңгысы хәзер һәркемне кызыксындыра булыр. Шәһәр халкы газ өчен бары тик саклык банкы бүлекчәләре аша сезгә түли башлады бит. Ә авылда банк бүлеге булмаса нишләргә? Норлатка кадәр барып мәшәкатьләнергәме?

- Һич юк. Бу очракта безнең идарә җирле үзидарә Советлары тәкъдим иткән материаль җаваплы затлар белән шартнамә төзи. Ул эш газ буенча слесарьларга да йөкләнә ала. Шартнамә нигезендә, аларга җыелган сумманың 2 проценты түләнелә.

- Ярар, монысы да аңлашылды. Владимир Васильевич, сезнең оешма буш җирлектә барлыкка килмәсә дә, проблемаларыгыз юк түгелдер. Финанс хәлегез ничегрәк?

- Проблемадан күп нәрсә юк. Һәркемгә мәгълүм, безнең идарә төзелгәнгә кадәр газ өчен түләү фатир өчен түләү белән бергә, йорт кем ведомствосында булса, шул предприятие һәм оешмага түләнелә һәм ул акчаның зур өлеше нәкъ шул предприятиеләр карамагында калып, бик азы гына шәһәр счетына керә иде. Нәтиҗәдә 1 апрельгә халыкның газдан файдаланган өчен бирәчәге 707 миллион сумга җыелган. Иң күп бурыч МППда (102.902 мең сум), МСОда 15.722 мең сум), «Родина» (63 миллион), Хафизов исемендәге (124 млн.), Кузнецов исем.(94 млн.), Синдряков исем. (65 млн.) КХАларда. Ә инде промышленность предприятиеләренең бирәчәге 10,3 миллиард сумга җитте. Әйтик, НГДУның газ өчен 1,6, МСОның 1,3, җылылык челтәренең 6,8 млрд. сум бурычы бар. (Бары тик Норлат шикәр заводы гына газ өчен түләп бетерде).

30 нчы йортлар идарәсенә дә дәгъвабыз бар. Ул челтәр газы өчен халыктан акчаны җыя да, Бөгелмәгә күчерә, ә менә газ белән тәэмин итүчеләр, ягъни безнең белән исәп - хисап ясамый. Моннан ары аларга газны да Бөгелмәдән ташырга туры килер мөгаен.

Хәзерге вакытта идарә халыкны, социаль - мәдәни объектларны һәм промышленность предприятиеләрен сыекландырылган газ белән тоткарлыксыз тәэмин итә. Үзвакытында һәм тулысынча түләү үткәргән очракта без газны лимиттан артыграк та бирә алабыз. Алдан түләп куйган промышленность предприятиеләренә 15 процент таштама каралган.

Безнең идарә алга таба да халык һәм предприятиеләр белән нормаль һәм эшлекле хезмәттәшлек итәчәгенә ышана һәм үз чиратында, газ белән тоткарлыксыз тәэмин итү, газ хуҗалыгына профилактика һәм ремонт эшләрен үткәрү өчен бар тырышлыгын куячак.

P.S. Газ өчен түләү мәсьәләсенә тагын әйләнеп кайтып, 2 апрельдә «Норлатгаз» идарәсе исеменә районга газ бирү күләменең 25 процентка кимелүе турында кисәткән телеграмма килгән. Әлеге дә баягы бурычларда хикмәт...

ТЕЛЕФОННАР: Газ чыкканда яки ул - бу була калганда 04, 5 - 13 - 96 номерлары буенча тәүлек буе шалтыратырга мөмкин. Өйләрдәге газ җиһазларын ремонтлату турында һәм баллонлы газга заказлар 5 - 13 - 96 телефоны буенча кабул ителә. Газ режимы бүлегенең телефоны 5 - 14 - 01, комплекслы службаныкы - 5 - 13 - 94, ПТОныкы - 5 - 14 - 02, бухгалтериянеке - 5 - 13 - 97, идарә начальнигыныкы - 5 - 13 - 95, баш инженерныкы - 5 - 13 - 99.

Хезмәтләре белән мактаулылар



- Комбинатта һөнәр алды, эшкә өйрәнде, тәҗрибә туплады, гаиләле булды,- диләр Анатолий Владимирович Терешин турында Норлат ит комбинатында. 18 яшеннән бирегә эшкә килеп, армиядән туры шунда кайтуы Анатолийның коллективны да, хезмәтен дә тиз үз итүен бәхәссез дәлилләүче факт.

Шунда 20 елдан артык эшләү чорында һөнәрен бар нечкәлекләренә кадәр өйрәнергә дә өлгерде. Ә һөнәре комбинат өчен бик мөһим аның, Анатолий Владимирович - суыткыч җайланмалары машинисты. Булдыклы, эшчән Терешин аларның һәрчак төзек булуын тәэмин итә.

Анатолий Владимировичны әйбәт гаилә башлыгы буларак та хөрмәтлиләр коллективта. Алар хатыны Любовь Александровна белән (ул шул ук комбинатта җыештыручы булып эшли) 3 бала үстерәләр, тату гомер итәләр.

Рәсемдә: суыткыч җайланмалары машинисты А.В.Терешин.
А.АЗИЗОВ фотосы.

Кем сөтне күбрәк сауды?

Саннарның беренче баганасы - быелның беренче кварталында бер сыердан савылган сөт, икенчесе - узган елның шул чорындагыдан артык яки ким, өченчесе - 3 апрельдә көнлек савым (килограммнарда).

«Дуслык»	1572	+19	22,1
«Кондырча»	1452	+665	17,1
Мичурин исем.	1014	+246	15,0
«Рассвет»	945	+57	12,5
«Сөлчә»	929	+292	13,2
«Родина»	892	+142	9,9
Хафизов исем.	858	+121	10,5
«Заветы Ильича»	838	+230	9,9
«Восход»	805	+537	12,5
М.Җәлил исем.	795	+208	9,0
«Татарстан»	791	+157	8,3
«Чирмешән»	790	+98	10,0
Якты Күл	775	+499	11,0
«Чишмә»	722	+213	11,0
Синдряков исем.	679	+126	8,6
«Правда»	653	+329	5,8
«Төрнәс»	642	+177	10,3
«Үрнәк»	627	+149	7,2
«Заря»	618	+235	7,4
Кузнецов исем.	617	+88	7,9
«40 лет Победы»	604	+135	7,8
Киекле	595	+160	8,6
«Москва»	592	+145	7,5
«Мамык»	539	+212	8,0
«Игенче»	521	+85	6,3
«Строитель»(МСО)	507	+80	6,8
Әлмәт	486	+59	6,7
«Таң»	433	+40	6,0
«Комбайн»	416	+85	5,7
«Алга»	406	+123	6,0
Район буенча	**689**	**+168**	**9,3**

Мәгълүматлардан күренгәнчә, беренче кварталда барлык хуҗалыкларда да диярлек сөт җитештерүдә алга таба зур адым ясалды. Шунысы куанычлы, алынган темп тотрыклы саклана. Әйтик, район буенча беренче кварталда бер сыердан савылган сөтнең 273 килограммы март аена туры килә. Узган елгыга караганда үсешнең дә яртысына якыны шушы айда ясалды. Ул яктан «Кондырча» һәм «Восход»та мартта 239 - 245, Якты Күл, «Правда», «Сөлчә», «Заря», «Төрнәс» хуҗалыкларында 119 - 139 килограмм үсешкә ирештеләр. «Рассвет»та да өч айда алга китеш 57 килограмм булса, мартта ул күрсәткеч 81 килограмм. Һәм моңа охшаш мисаллар тагын да бар.

Апрельдә дә савым тотрыклы. Бүген район буенча бер сыердан көнлек авым узган елның шул чорындагыдан 2,8 килограммга күбрәк. «Таң»нан кала барлык хуҗалыкларда да плюс белән баралар. Иң зур плюс хәзер «Восход»та һәм «Дуслык»та (8,3 - 8,4 килограмм) һәм «Кондырча»да (7,3 килограмм). «Чишмә», Якты Күл, «Рассвет», «Төрнәс» хуҗалыкларында бу күрсәткеч 4,1 - 4,5 килограмм.

Матбугат - 97

«Дуслык»ка льготалы язылу!

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Апрельнең 10сына кадәр «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына льготалы бәягә, ягъни 16.200 сумга гына язылып калырга мөмкин.

Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!

Районыбыз хәбәрләр тормышыннан

Язгы ярминкә буласы

Гомумрайон бәйрәмнәре җыелмасына тагын бер чара кушылырга тора - язгы, апрель ярминкәсе. Киләчәктә аның да традиционга әйләнүе ихтимал.

Бу бәйрәм палитрасы бай һәм киңкырлы. Анда район кулланучылар җәмгыяте, эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре, крестьян - фермер хуҗалыклары ассоциацияләре, шәһәр предприятиеләре һәм шәхси эшмәкәрләр сату итәчәк. Сәүдә шәһәрчегеннән тыш, программага традицион ат чабышлары һәм спорт ярышлары, район үзешчәннәре концерты кертелә. Ярминкә аэропорт мәйданында үткәреләчәк. Быелгы яз салкын, соңарып та килә, шуңа алда әле мәшәкатьләр шактый тора: чабу юлларын, сәүдә рәтләрен, мәдәни - спорт чаралары үткәреләчәк урыннарны кардан чистартасы бар.

Боларның барысы хакында да 2 апрельдә район хакимиятендә шәһәр предприятиеләре, оешмалары һәм кайбер КХАлар җитәкчеләре катнашында узган киңәшмәдә җитди сүз булды. Аны хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев алып барды. Киңәшмәдә район хакимияте башлыгы урынбасалары Ф.Р.Ногъманова, ярминкәне уздыру комиссиясе рәисе Ф.Н.Гобәйдуллин, район кулланучылар җәмгыяте рәисе М.С.Моратов чыгыш ясадылар.

Министр килеп китте

4 апрельдә районда Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләр министры Валерий Александрович Власов булып китте. Ул Октябрь урман хуҗалыгында, «Родина» һәм Кузнецов исемендәге крестьян һәм фермер хуҗалыклары ассоциацияләрендә булды. Район җитәкчелеге белән очрашуда язгы ташуга каршы чаралар тикшерелде.

Иртәгә - Геологлар көне

Алдагы көнгә өмет белән карыйбыз

Апрель башында Геологлар көне билгеләп үтелә. Гадәттә бәйрәм алдыннан моңарчы башкарылган эшләргә йомгак ясала, ирешелгән уңышлар белән бергә, алга таба бурычлар да билгеләнә.

Ул яктан безнең нефть - газ чыгару идарәсе иң элек нефть запасларын арттыру заданиеләрен уңышлы башкарып килә. Хәзерге вакытта коллектив 11 нефть чыганагында промышленность эшкәртүе алып бара. Алар арасында Бурейка, Вишневая Поляна, Норлат, Аксубай - Мокшино, Котыш, Ивашкино - Кече Сөлчә чыганаклары бар. Болардан тыш промышленность максатларында эшкәртүгә әзерләнгән чыганаклар да берничә.

Геологик эзләнү эшләренең фәнни нигезләнгән дәрес юнәлешен сайлау геологик заданиеләрне үтәүдә мөһим алшартларның берсе булып тора. Ул җәһәттән соңгы елларда геологик эзләнү эшләренең нәтиҗәлелеге сизелерлек күтәрелде һәм шуның нәтиҗәсе буларак катламнардан нефть алуның коэффициенты үсте.

Бөтен коллективның уртак тырышлыгы уңай нәтиҗәсен бирми калмый. Идарә җитештерү заданиеләрен елның елында уңышлы үтәп килә. Уртак нәтиҗәдә чыганакларны геологик эшкәртү белән шөгыльләнүчеләрнең дә өлеше саллы. Нәкъ менә геологлар нефть чыгаруда үзәк постларны алып торалар. Алар эшкәртелә торган нефть һәм газ чыганакларының геологик шартларын ачыклыйлар, нефть һәм газ запасының торышына контрольлек итәләр. Чыганакларны файдалануның дөрес режимын сайлау, нефть чыгаруда, скважиналарны тикшерүдә иң яңа технологияләр кертү - шулай ук геологик службаның бурычы.

Безнең идарәнең геологик службасында тиешле белемгә ия, югары квалификацияле белгечләр эшли. Геологик бүлек начальнигы Р.Х.Әхмәтҗанов, фәнни - тикшеренү һәм җитештерү эшләре цехы начальнигы А.В.Кормухин биредә - идарә оешканнан бирле. I категорияле геолог Р.Г.Галиева, нефть һәм газ чыгару буенча беренче цехның әйдәп баручы геологы В.Н.Лапкин идарәдә 15 ел һәм аннан да күбрәк эшлиләр инде. Моннан тугыз ел чамасы элек Мәскәү нефть һәм газ институтын тәмамлап безгә яшь белгеч И.З.Мәннапов килгән иде. Хезмәт юлын нефть чыгару операторы булып башлады ул, аннан мастер итеп күчерелде. Хәзер ул төп бүлекләрнең берсен - нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү бүлеген җитәкли. Җыеп кына әйткәндә, геологик службада үз эшләрен нечкәлекләренә кадәр белүче һәм аны көн таләпләре югарылыгында алып баручы тырыш белгечләр тупланган.

Норлат нефтьчеләре алдагы көнгә өмет белән карыйлар. Аларның үсеш перспективасы да бар. Нефть чыгару күләме елдан ел арта бара әле. Бу уңайдан безнең идарә нефтьнең шактый өлеше югары үзлелекле, сумалалары һәм күкерте күп булган, чыганакларын эшкәртү белән шөгыльләнүен дә әйтергә кирәк. Андый ятмаларны традицион юллар белән эшкәртү темпны да төшерә, катламнарның нефть бирүчәнлеге дә түбән кала. Шуңа күрә идарәдә авыр алына торган запасларны чыгаруның гидродинамик һәм физик - химик ысулларын куллану системасын камилләштерү эше алып барыла, нефть чыгаруның алдынгы технологияләре кертелә. Һәм барлык бу эшләрдә геологларга үзәк бурычлар йөкләнә.

Заманында геолог хезмәте күпләрне романтикасы белән үзенә тарта иде. Әмма нефть чыгару предприятиесендәге геологларның эше күп вакыт кабинетларда, төрле анализлар һәм тикшеренүләр уздыру белән уза. Әллә никадәр ашыгыч заданиеләр үтәргә туры килә аларга. Һәм безнең геологлар сызган - төзегән схема, таблицаларны бер җепкә тезсәң, мөгаен Норлаттан Татарстанның нефть башкаласы Әлмәткә кадәр сузылыр иде.

Форсаттан файдаланып, бүген геология хезмәтенә катнашы булган һәркемне һөнәри бәйрәмебез белән котлыйм.

Ш.ГЫЙЛӘҖЕВ,
НГДУның баш геологы.

Сезгә җавап бирәләр

«Ачык хатлар көне»ндә район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин һәм службалар җитәкчеләре исеменә юлланган хатларга җаваплар урнаштыруны дәвам итәбез.

Торак кемгә тиешле?

Сорау: НГДУда мин 15 елдан артык эшләдем, әмма хәзергә кадәр фатир ала алмадым. Чиратым җитеп килә, инде фатирларны түләүле диләр. Бу ничек була инде?

«Норлатнефть» НГДУсы начальнигы М.Хуҗин, профком рәисе О.Лизунов кул куйган җавапта түбәндәге аңлатма бирелә:

«Татнефть» акционерлар җәмгыяте директорлар советы карары белән (25 декабрь, 1996 елдан 7 номерлы беркетмә) «Татнефть» акционерлык җәмгыятенә караган торакларны милек хокукында реализацияләү турында вакытлыча Положение расланды.

Бу положение белән «Татнефть» АҖнә караган торакларны реализацияләү тәртибе билгеләнә. Торакны сатканда хезмәткәрнең тораккa мохтаҗлыгы, торак алуга чираты исәпкә алына.

Сату - алу килешүе төзегәндә «Татнефть» АҖ исәбенә байтак компенсация карала. Анда торак шартларын яхшырту буенча учетка басканнан соң узган вакыт, бер гаилә әгъзасының кереме, гаилә членнарының барысының да «Татнефть» АҖндә гомуми эш стажлары исәпкә алына. Торакның сыйфат коэффициенты да шунда кертелә. Торак алганда компенсация күләме 1 бүлмәле фатир өчен 50 миллион сум,ике бүлмәлегә 75 миллион, 3 бүлмәлегә 100 миллион сумга җитәргә мөмкин. Сату - алу килешүендә калган түләүнең бер өлешен хезмәткәр эш хакының 30 проценты күләмендә ай саен түләү шарты да карала ала. Шулай ук алынган торакны өлешчә түләү шарты белән үз (хосусыйлаштырылган) торагыңны «Татнефть» АҖнә тапшырырга да мөмкин.

Йорт салырга ниятлиләр

Норлат геофизик эшләр идарәсенең яңа җитәкчелегенә әйбәт мирас тапшырылмады. Соңгы елларда эш күләме кимү, үзара түләмәүчелек, нәтиҗәдә производство күрсәткечләренең бермә - бер кимүе, башкарылган эш күләменнән кергән табышның салымнар түләргә дә җитмәве идарәне кризис хәленә китерде. НУГР карамагындагы ике - Төзүчеләр һәм Молодежная урамнарындагы щитовой йортлар тузды, анда яшәүче халык юлсызлыктан, утсызлыктан, җылысыз калудан җәфа чигеп яши. Әлбәттә, зур югалтулар белән, табышсыз көн күрүче идарәнең йортларны төзекләндерергә дә, урамнарны һәм башкаларын тәртипкә китерергә дә бер нинди җае да, мөмкинлеге дә юк. Аңлашыла ки, 160лап кеше исәпләнгән коллективның да хәле кызыгырлык түгел, көннән - көн эшсез утырып калу куркынычы яный башлады.

Шул рәвешчә идарәнең киләчәгенә кагылган мәсьәләләр башкалада, югары җитәкчелек каршында кузгатылды. Һәм нәтиҗәсе буш булмады диергә мөмкин: идарә начальнигы В.Г.Наумов әйтүенчә, республика хөкүмәте НУГРга 30 фатирлы йорт салу өчен 5 миллиард сум акча бүленәчәгенә ышандыра. Бу җылы хәбәр коллективның кәефенә яңа сулыш, өметләр алып килми калмас, мөгаен. Төзелешне «53 нче СМУ» ОООсы алып барыр дип ниятләнә.

Димәк, кыскартылу куркынычы әлегә тынып кала. Бары тик НУГРның котельнясында эшләүче өч кеше генә аңардан котылып кала алмады: «Котельня иске, тузган, идарәгә файда түгел, чыгымнары да зур булганга бары тик зыян гына китерә», ди бу хакта идарә начальнигы. Шуңа да котельня ябылып, биредәге җылылык системасы үзәк челтәргә тоташтырылды.

Ф.ЗЫЯТДИНОВА.

Ссуданы - 31 процент белән

Россия саклык банкы идарәсе быелныңике аенда халыкка ссуда бирү буенча процент ставкаларын өч тапкыр төшерде инде: гыйнвар аенда 45 процентлык ставка 37гә, февральдә 31гә калды. Бу икътисадны тотрыклыландыру процессы һәм халыкның тормыш дәрәҗәсе төшүен күздә тотып эшләнәдиелә саклык банкы идарәсе карарында. Аңлашыла ки, бу хәбәр кайберәүләрне бик куандырды: саклык банкының район бүлеге хезмәткәрләре әйтүенчә, ссуда сорап килүчеләр саны көннән - көн арта. Кемдер өй җиһазы, машина юнәтә. Кыскасы, чыннан да тормыш дәрәҗәсен күтәрү өчен җайлы чара.

Аның каравы, булган акчаны кассага салып процентлар арттыру мөмкинлеге артта калды: вкладларга арта торган процент суммасы сизелерлек төштә. Сроклы вкладлар бер айга 1,4 процентка, номерлылар 1,7гә, сорап алганга кадәр салынган вклад 2 процентка арта, пенсия һәм балалар өчен максатчан вкладлар елына 20 һәм 28 процентларга үсә. Сроклы депозитлар буенча да процентлар зур түгел: суммасына һәм салыну вакытына карап алар елына 17дән 25кә кадәр тирбәләләр.

Пенсиядә булса да

Рәшит Мөхәммәтшинович электромеханик һөнәренең нечкәлекләрен зур хезмәт тәҗрибәсе аша белә. Тулы эш стажын тутырып пенсиягә киткәч тә, өйдә тыныч яшәп утырырга теләмәде ул - менә дүртенче елын инде яңа элеваторда мастер - энергетик булып эшли. Хезмәтен ипле генә һәм сыйфатлы итеп башкара. Тыныч, сабыр, ярдәмчел холкы аркасында ул коллективта да абруйлы.

Рәсемдә: элеватор эшчесе Р.Галиев.

Н.АЗИЗОВ фотосы.

ПАТРИОТЛАР ТӘРБИЯЛӘРГӘ

(Ветераннарның район Советында)

Хезмәт һәм сугыш ветераннары район Советының күптән түгел булып узган киңәйтелгән утырышында яшьләргә хәрби - патриотик һәм интернациональ тәрбия бирү һәм аларны Кораллы Көчләрдә хезмәт итүгә хәзерләү мәсьәләсе каралды.

Безнең районда бу юнәлештә билгеле күләмдә эш алып барыла. Мәктәпләрдә укучыларның сугыш ветераннары белән очрашулары үткәрелә. Батырлык дәресләрендә ветераннар патриотизм, Ватанны саклау кебек изге бурыч, безнең районда яшәүче күпмилләтле халыкларның дуслыгы турында әңгәмә коралар. Укучылар һәйкәлләр һәм хәрбиләр каберләрен дә карап торалар.

Ел саен Советлар Союзы Геройлары Н.К.Синдряков, А.Н.Кузнецов призына чаңгы, Н.А.Козлов призына җиңел атлетика, өч дәрәҗә Дан орденнары кавалерлары П.Е.Михеев, М.М.Мәсгутов призларына футбол һәм милли көрәш, Түбән Норлаттан Әфганстанда һәлак булган М.Бакиров истәлегенә шулай ук милли көрәш буенча ярышлар үткәрелә.

Элеккеге әфганлылар да мәктәпләрдә еш кунак. Әфганстанда һәлак булган биш якташыбыз истәлегенә һәйкәл төзелде, Норлат урамнарына аларның исемнәре бирелде.

Хәрби комиссариат каршында сугыш һәм хезмәт ветераннарыннан торган комиссия эшли. Алар хәрби хезмәткә чакырылучылар алдында Ватанны саклау кебек изге эш турында әңгәмәләр үткәрәләр.

«Дуслык» район газетасында даими рәвештә «Россиянең хәрби даны көннәре» рубрикасы алып барыла.

Утырышта бу эшкә тагын да киңрәк колач һәм максатчан юнәлеш бирү кирәклеге әйтелде. Аерым алганда, мәктәпләрдә «Ягез әле, егетләр!» конкурсларын, «Аҗаган» уенын үткәрергә кирәк. Авылларда, предприятиеләрдә егетләрне тантаналы төстә хәрби хезмәткә озатуны оештырырга, кайтканнарын шундый ук төстә каршы алып, эшкә урнашканчыга кадәр бирелә торган пособие тапшырырга кирәк.

Җирле үзидарәләр органнары һәм хуҗалыклар җитәкчеләренә хәрби хезмәткә алынучыларны хәрби комиссариатка озату өчен транспорт бирү мәсьәләсен оператив хәл итү зарури. Урыннардагы ветераннар советларыннан бу чараларны үткәрүдә актив катнашу сорала.

И.САНДЛЕР,
сугыш ветераннарының район Советы президиумы әгъзасы.

TV

ПОНЕДЕЛЬНИК, 7 АПРЕЛЯ «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан"
18.15 Мультфильмы
18.25 Балалар өчен "Тамчы"
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Под созвездием Лиры". Композиторы - детям
19.30 "Служба 01"
19.45,21.45 Новости
20.00 "Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар". Актер Ә.Шакиров
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Беренче мәхәббәт"
21.15 "Авыл"
22.00 "Карт - бланш". Наш гость - Юрий Стоянов
22.30 "Виртуальная реальность"

ОРТ

6.35 "Доброе утро"
9.00 12.00 15.00 18.00 0.55 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
9.55 Поле чудес.
11.00 Человек и закон.
11.30 19.35 "Угадай мелодию".
12.15 "Картуш" Х.ф
14.25 Футбольное обозрение.
15.20 "Легенды острова сокровищ".
15.45 Марафон-15.
16.05 Звездный час.
16.40 "Нико и его друзья".
17.10 ...До 16 и старше.
17.35 Вокруг света.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
20.05 "Человек в маске".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.45 "Полтергейст" Х.ф
22.40 Белла Ахмадулина в цикле "Жизнь замечательных людей".
23.10 "Плюмбум, или Опасная игра" Х.ф
1.05 Пресс-экспресс.

"РОССИЯ"

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести
7.15 8.15 С добрым утром!
9.00 Программа передач. 9.05 16.30 "Клубничка".
9.35 Сам себе режиссер.
10.10 19.05 "Санта-Барбара".
11.15 Парламентский вестник.
11.45 Графоман.
11.55 "Берега". Х/ф
13.10 "Ваше сословие".
13.40 Ретро-шлягер.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "ТИ-Маркет".
14.25 "Автограф".
14.30 "Наш, всегда наш..."
14.55 "Репортаж ни о чем".
15.10 "Иванов, Петров, Сидоров и другие".
15.50 Вместе.
16.20 "Палиха, 14".
16.25 0.45 "Товары - почтой".
17.15 Там-там новости.
17.25 Лукоморье.
17.50 Посмотри на себя.
18.00 Красная книга.
18.15 Пульс.
18.45 Россияне.
20.35 Добрый вечер.
21.15 "Паспорт". Х/ф.
23.35 "На коне". Телелотерея.
23.50 "Дежурная часть".
0.15 Частная коллекция.
1.05 "Телемагазин".

РИО

20.00 "Шесть самарских новостей"
20.05 "Студия ДВА"
20.55 22.00 0.45 "Шесть новостей"
21.05 Ток-шоу "МУЗЫКА И ПРЕССА": "АКУЛЫ ПЕРА".
22.15 "Испытание верности"Х.ф
00.1 Катастрофы недели.
01.00 Дорожный патруль

ВТОРНИК, 8 АПРЕЛЯ «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан".
18.05 Мультфильмы
18.45, 20.45 "Җиһан"
19.00 Музыкаль тәнәфәстә
19.10 "Карт - бланш". Наш гость - Ренат Ибрагимов
19.45,21.45 Новости
20.00 "На соискание Государственной премии Татарстана им Г.Тукая". Художник А.Абзгильдин
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Андрей Рублев". 1-я серия

ОРТ

6.35 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 23.40 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 "Человек в маске". 10.55 Смехопанорама.
11.30 19.35 "Угадай мелодию".,
12.15 "Мушкетеры двадцать лет спустя".
13.20 Мультфильм.
13.40 Очевидное - невероятное.
14.10 "Боль сердца" Х.ф
15.20 "Легенды острова сокровищ".
15.45 Кварьете "Веселая квампания".
15.55 Мультитроллия.
16.15 Волшебный мир, или Синема.
16.40 "Нико и его друзья".
17.10 ...До 16 и старше.
17.35 Вокруг света.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
20.05 Тема.
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.45 "Пьеса для пассажира" Х.ф
23.50"50 Х 50".
0.35 Пресс-экспресс.

"РОССИЯ"

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.05 16.30 "Клубничка"
9.35 Караоке по-русски. 10.10 19.05 "Санта-Барбара".
11.15 Пульс. Правительственные будни.
11.45 Графоман до 11.58.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "ТИ-Маркет".
14.25 "Автограф".
14.30 Арена для сенсаций.
14.55 Мультфильм.
15.10 "Иванов, Петров, Сидоров и другие".
15.50 Образ жизни.
16.20 "Манекен".
16.25 1.30 "Товары - почтой".
17.15 Там-там новости.
17.25 Лукоморье.
17.50 Посмотри на себя.
18.00 Красная книга.
18.15 Новое пятое колесо.
18.45 Россияне.
20.35 Добрый вечер.
21.20 "Девичья весна". Х/ф.
23.35 Момент истины.
0.00 Звуковая дорожка.
1.20 "Телемагазин".

РИО

20.00 "Шесть самарских новостей"
20.05 "Студия ДВА"
20.55 22.00 0.45 "Шесть новостей"
21.05 Ток-шоу "Я САМА".
22.15 Сериал "Династия II (Семья Колби)", 11 серия
23.10 Те Кто
23.40 "Новые мстители" Х.ф
00.35 "Шоу Бенни Хилла"
01.00 Дорожный патруль

СРЕДА, 9 АПРЕЛЯ «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 "Чулпан"
18.05 Мультфильмы
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Авыл"
19.30 "Три бардовских аккорда..."
19.45,21.45 Новости
20.00 "Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар". Җырчы В.Ганиева
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Андрей Рублев". 2-я серия

ОРТ

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 23.20 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 Тема.
10.50 В мире животных.
11.30 19.35"Угадай мелодию".
12.15 "Мушкетеры двадцать лет спустя".
13.40 "Колесо истории".
14.25 Служу России!
15.20 "Легенды острова сокровищ".
15.45 Кактус и К.
15.55 До-ми-соль.
16.15 Зов джунглей.
16.40 "Нико и его друзья".
17.10 ...До 16 и старше.
17.35 Вокруг света.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
20.00 "В поисках утраченного".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!".
21.00 Время.
21.45 Смехопанорама.
22.20 0.30 Футбол. Лига чемпионов. Полуфинал.
0.20 Пресс-экспресс.

"РОССИЯ"

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.05 16.30"Клубничка".
9.35 L-клуб.
10.10 19.05 "Санта-Барбара".
11.15 Новое пятое колесо.
11.45 Графоман.
11.55 "Берега". Х/ф.
13.10 Мультфильм.
13.25 "Точка опоры".
13.40 Ретро-шлягер.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "ТИ-Маркет".
14.25 "Автограф".
14.30 Театр моей памяти.
14.55 Ноу-хау.
15.10 "Иванов, Петров, Сидоров и другие".
15.50 Соотечественники.
16.20 "Эксповестник".
17.15 Там-там новости.
17.50 Посмотри на себя.
18.00 Ваше право.
18.15 Люди, деньги, жизнь.
18.45 Россияне.
20.35 Добрый вечер.
21.20 "Криминальный квартет". Х/ф.
23.35 Подиум Д"арт.
0.15 Кафе Обломов.
1.15 "Телемагазин".

РИО

20.00 "Шесть самарских новостей"
20.05 "Студия ДВА"
20.55 22.00 0.45 "Шесть новостей"
21.05 Ток-шоу "Я САМА".
22.15 Сериал "Династия II (Семья Колби)", 10 серия
23.10 Те Кто.
23.40 "Новые мстители".
0.35 "Шоу Бенни Хилла" 01.00 Дорожный патруль

ЧЕТВЕРГ, 10 АПРЕЛЯ «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 "Чулпан"
18.05 Мультфильмы
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 Концерт оркестра народных инструментов под управлением А.Шутикова
19.25 "Слово депутата"
19.45,21.45 Новости
20.00 "ГАИ - информ"
20.10 "Әлли - бәлли - бәү"
20.30 "Беренче мәхәббәт"
21.00 "Кинотеатр "Парадизо". Х/ф.
22.40 Эхо голоса твоего

ОРТ

6.00"Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.05 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 "В поисках утраченного".
10.50 Клуб путешественников.
11.35 Смак.
12.15 "Мушкетеры двадцать лет спустя".
13.35 Футбол.
15.20 "Легенды острова сокровищ".
15.45 "Остров Чунга-Чанга".
16.05 До-ми-соль.
16.40 "Нико и его друзья".
17.10 ...До 16 и старше.
17.35 Вокруг света.
18.20 "Девушка по имени Судьба".
19.00 Погода.
19.05 Час пик.
19.30 Джентльмен-шоу. 20.00 Моя семья.
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.45"Готовое платье"Х.ф
0.15 Фестиваль эстрадной песни в Сан-Ремо.
0.50 Пресс-экспресс.

"РОССИЯ"

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.00 Программа передач. 9.05 16.30 "Клубничка".
9.35 Бесконечное путешествие.
10.10 19.05 "Санта-Барбара".
11.15 "Люди. Деньги. Жизнь".
11.45 Графоман.
11.55 "Берега". Х/ф.
13.10 Мультфильмы.
13.25 "Точка опоры".
13.40 Ретро-шлягер.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "ТИ-Маркет".
14.25 "Автограф".
14.30 Царская ложа.
15.10 "Иванов, Петров, Сидоров и другие".
15.50 На пороге века.
16.20 "Ваш партнер".
16.25 0.40 "Товары - почтой".
17.15 Там-там новости.
17.25 Лукоморье.
17.50 Посмотри на себя.
18.00 Темная для А.Волкова.
18.15 Избранные.
18.45 Россияне.
20.35 Добрый вечер.
21.20"Моя любовь" Х.ф
22.45 М/ф для взрослых.
23.35 "Белла". К юбилею Б.Ахмадулиной.
0.00 По вашим письмам.
1.00 "Телемагазин".

РИО

20.00 "Шесть самарских новостей".
20.05 "Студия ДВА"
20.55 22.00 0.45 "Шесть новостей"
21.05 Ток-шоу "СДЕЛАЙ ШАГ"
22.15 Сериал "Династия II (Семья Колби)".
23.10 Те Кто
23.40 "Новые мстители"
00.35 "Шоу Бенни Хилла"
01.00 Дорожный патруль

ПЯТНИЦА, 11 АПРЕЛЯ «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.50 Мультфильмы
18.15 "Легенды древних гор". Х/ф. (на тат.яз.)
18.45,20.45 "Җиһан"
19.45,21.45 Новости
20.00 "В Госсовете Татарстана"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Җомга көн кич белән"
22.00 "Досье 02"
22.15 "Видеоспрт
22.30 "Свет ее души". Лима Кустабаева

ОРТ

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 23.55 Новости.
9.15 18.20"Девушка по имени Судьба".
10.05 Моя семья.
10.50 Пока все дома.
11.25 Играй, гармонь любимая!
12.15 "Мушкетеры двадцать лет спустя".
13.55 Джентльмен-шоу.
14.25 Мультфильмы.
15.20 "Легенды острова сокровищ".
15.45 Фильм-сказка.
17.05 ...До 16 и старше.
17.30 Магия: мир сверхъестественного.
18.20 "Девушка по имени Судьба".
19.10 Погода.
19.15 Человек и закон.
19.45 Поле чудес.
20.45 "Спокойной ночи, малыши!".
21.00 Время.
21.45Коломбо в детективе "Стивен Спилберг спешит на помощь".
23.10 Взгляд.
0.05 "От заката до рассвета" Х.ф
2.00 Пресс-экспресс.

"РОССИЯ"

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.05 16.30 "Клубничка".
9.35 "Аншлаг" представляет.
10.10 19.05 "Санта-Барбара".
11.15 Избранные.
11.45 Графоман.
11.55 "Берега". Х/ф.
13.05 Минарет.
13.20 "Точка опоры".
13.35 Ретро-шлягер.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "ТИ-Маркет".
14.25 "Автограф".
14.30 Момент истины.
14.55 Репортер.
15.10 "Иванов, Петров, Сидоров и другие".
15.50 Золотая карта России.
16.20 "Палиха, 14".
16.25 0.55 "Товары - почтой".
17.15 Там-там новости.
17.25 Лукоморье.
17.45 Посмотри на себя.
18.00 Ничего кроме.
18.15 Парламентский вестник.
18.45 Россияне.
20.35 Добрый вечер.
21.20 "Очень верная жена". Х/ф.
22.45 М/ф для взрослых.
23.35 Тихий дом. Программа С.Шолохова.
0.15 Ночной экспресс.
1.15 "Телемагазин".

РИО

20.00 "Шесть самарских новостей"
20.05 "Студия ДВА"
20.55 "Отдел по расследованию убийств" Х.ф
22.50 01.20 "Шесть новостей"
23.05 Клуб "12 КОПЕЕК"
23.30 "Приговор"Х.ф
01.35 Дорожный патруль

СУББОТА, 12 АПРЕЛЯ «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.40 Мультфильм
18.00 "Мактанчык куян". Балалар өчен телеспектакль
18.45 "Җиһан"
19.00 "Бизнес - коктейль". Программа для деловых людей.
19.30 "Тукай аһәңнәре". Э.Җәләлетдинов башкара
19.45 Новости
20.00 Из "личной жизни"...дома
20.05 "Әлли - бәлли - бәү"
20.20 Лопе де Вега. "Бию-че". Г.Камал исемендәге татар Дәүләт академия театры спектакле

ОРТ

8.00 "Москва-Кассиопея".
9.25 Мультсериал.
9.45 Домашняя библиотека.
10.00 15.00 18.00 Новости.
10.10 Слово пастыря. Митрополит Кирилл.
10.30 Не зевай!
11.00 Утренняя почта.
11.35 Смак.
11.55"Приглашение к музыке".
12.35 "Дорогой мой человек"Х.ф
14.25 Очевидное - невероятное.
15.20 Звезды о звездах в ток-шоу "Поехали!".
16.00 Мультфильм.
16.15 В мире животных.
16.55 Футбол. Чемпионат России.
19.00 Погода.
19.05 "Каламбур"
19.40 "Затерянные во времени"Х.ф
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.50 "Укрощение огня"Х.ф
1.00 София Ротару в концертной программе "Кумиры, кумиры...".

"РОССИЯ"

8.00 Утренний экспресс.
8.55 "Медицинский вестник".
9.05 Меморина. Телеигра.
9.30 "Клуб "Адреналин".
9.45 Доброе утро, страна!
10.30 В мире животных.
11.00 14.00 20.00 23.00 Вести.
11.15 "Хотите сниматься в кино?".
11.55 "Романсиада-97". 12.05 Лучшие игры НБА.
13.00 "Анонимные собеседники".
13.30 "Поэт в России - больше, чем поэт".
14.25"Россия в войне. Кровь на снегу"Д.ф
15.20 Караоке по-русски.
15.50 Двойной портрет.
16.15 Бесконечное путешествие.
16.45 Мужчина и женщина.
17.30 Телескоп.
18.10 "Живьем в "России". Концерт А.Градского.
20.35 Сам себе режиссер.
21.10 "Молчаливый партнер". Х/ф
23.15 Момент истины.
0.10 Репортер.
0.25 Программа "А".
1.00 София Ротару в концертной программе "Кумиры, кумиры..."

РИО

9.00 "Шесть самарских новостей".
9.05 Программа "Благая Весть"
9.35 "РИО-МАРКЕТ".
10.00 01.10"Шесть новостей"
10.10 Дорожный патруль
10.25 Детский сеанс. "Крепыш".
12.00 Мультфильмы.
12.55 Программа для детей "Это мы не проходили".
13.25 "Дикая природа Австралии"
14.25 ОТКРЫТИЯ НЕДЕЛИ
15.05 "КИНЕСКОП".
16.05 ДИСК-канал для детей
16.55 Ток-шоу "Я САМА": "Золотая лихорадка"
17.55 Ток-шоу "ПРОФЕССИЯ": "Космонавт"
18.50 "Клуб одиноких сердец"
19.20 Сериал по выходным "Жара в Акапулько"
20.05 "Десерт". ТЦ "ЛИК" (г. Тольятти)
20.20 "Сызранские вести". КТВ "ЛУЧ" (г. Сызрань)
20.40 "Домовой". Тележурнал.
21.05 Сериал по выходным "Жара в Акапулько"
21.55 СКАНДАЛЫ НЕДЕЛИ
22.30 Юмористическая программа.
23.15 Фитиль"
23.30 "Его звали Роберт"
01.25 "ОБОЗ"
02.35 Дорожный патруль

ВОСКРЕСЕНЬЕ, 13 АПРЕЛЯ «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.10 Мультфильм
17.30 Фильм - детям. "Мама"
19.00 "Хрустальная пирамида".
19.30 "ТОН"
20.15 "Автокалейдоскоп"
20.30 "Телебуклет"
20.40 "Әлли - бәлли - бәү"
20.50 "Сәхнә". Яшь талантлар
21.50 Г.Зарипов. "Уен". Телевизион спектакль

ОРТ

8.00 "Отроки во вселенной".
9.25 М/ф нашего детства.
10.00 15.00 0.45 Новости.
10.15 "Непутевые заметки" Дм.Крылова.
10.30 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 Служу России!
12.30 Играй, гармонь любимая!
13.00 Провинциальные истории.
13.20 Сериал "Подводная одиссея команды Кусто".
14.20 Смехопанорама.
15.20 "Симфонические тайны".
15.45 Клуб путешественников.
16.30 Возвращение Третьяковки.
16.55 Мультфейерверк. 17.40 "Один на один".
18.10 Счастливый случай.
19.00 Погода.
19.10 Клуб "Белый попугай".
20.00 "Затерянные во времени"Х.ф
20.50 Киноафиша.
21.00 Время.
21.40 Футбольное обозрение.
22.00 "Криминальное чтиво".

"РОССИЯ"

7.00 Утренний экспресс.
8.55 "Торговый дом "Ле Монти".
9.10 "Солти" Х.ф
.35 "У всех на устах".
9.50 Доброе утро, страна!
10.30 Присяга.
11.00 14.00 23.00 Вести.
11.15 Русское лото.
11.55 "Мода".
12.00 Книжная лавка.
12.25 Наш сад.
12.50 Музыка на десерт. 13.05 Человек на земле. 13.30 "Сад культуры".
14.25 "Россия в войне. Кровь на снегу" Д.ф
15.20 Волшебный мир Диснея.
16.15 "Репортаж ни о чем".
16.30 Довгань-шоу.
17.00 Весь мир.
17.40 Вечер с А.Гурновым.
17.55 "Один против всех".
18.10 "Удивительный мир".
18.25 L-клуб.
18.55 РТР в гостях у телезрителей.
19.10 "Аншлаг"
19.40 "Ситуация".
20.00 Зеркало.
21.00 "Городок".
21.35 Футбол без границ.
22.05 Нобелевские лауреаты.
22.50 "К-2" представляет.
23.45 У Ксюши.
0.15 "Пища богов - II". Х/ф
1.50 "Гороскоп".

РИО

9.00 "Шесть самарских новостей"
9.30 СКАНДАЛЫ НЕДЕЛИ
10.00 "Шесть новостей" 10.10 Дорожный патруль 10.25 Мультсериал.
11.15 "Золотой тюлень"
12.55 "ПАЛЬЧИКИ ОБЛИЖЕШЬ".
13.30 Юмористическая программа.
13.55 "Дикая природа Австралии"
14.55 "КАНОН"
15.25 МУЗЫКА КИНО.
15.35 Ток-шоу "МУЗЫКА И ПРЕССА".
16.30 Ток-шоу "СДЕЛАЙ ШАГ"
17.25 Спорт недели.
17.55 Концерт Олега ГАЗМАНОВА.
18.55 "Европа плюс".
19.25 Сериал по выходным "Жара в Акапулько"
20.10 "РИО-МАРКЕТ".
21.15 "Жара в Акапулько"
22.10"Фитиль"
23.25 "Солярис" Х.ф
01.35 "Шоу Бенни Хилла"
02.10 "Партийная зона."

Укырга керергә теләүчеләргә

Күптән түгел Норлатка Түбән Кама шәһәренең Г. Тукай исемендәге төрек - татар лицееннан вәкилләр килеп китте. Октябрь районы халкына үз максатларын белдерү, лицей белән таныштыру йөзеннән алар безнең редакциягә дә керделәр. Укучыларга лицей мәдире Челик ИБРАҺИМ бәй белән әңгәмә тәкъдим итәбез.

ТӨРЕК - ТАТАР ЛИЦЕЕ ЧАКЫРА

- Безнең лицей Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы һәм Төркия Республикасының милли белем бирү министрлыгы килешүе нигезендә 1993 - 1994 нче елгы уку елында ачылды. Бүгенге көндә Татарстанда 7 татар - төрек лицее бар, шуларның берсе - безнекендә бүгенге көндә 25әр укучыдан торган ике группа белем ала.

1995 - 96 нчы уку елына кадәр безнең лицейга гомуми белем бирү мәктәбендә 8 классны тәмамлаучы яшүсмерләр генә кабул ителә иде, 1996 - 97 нче уку елыннан 6 нчы һәм 8 нче классларны тәмамлаучы малайларны ала башладык. Әйтергә кирәк, лицейга керергә теләүчеләр бик күп, үткән ел 552 кешедән бары тик 50се генә конкурстан үтте.

- Төп фәннәр кайсы телдә алып барыла? Укытучылар кайдан җыелган?

- Беренче уку елы - әзерләнү елы, ул тирәнтен итеп инглиз һәм төрек телләрен өйрәнүгә багышлана. Алдагы елларда төгәл фәннәр - инглиз, гуманитар фәннәр төрек телләрендә укытылачак. 6 классны тәмамлаучылар 5 ел, 8 нчедән соң 4 ел белем алалар.

Лицейдагы әйдәп баручы укытучылар һәм тәрбиячеләр Төркиядән килгән, шуңа да белем бирү дөнья стандарты таләпләренә җавап бирерлек. Безнең лицей гомуми урта белем биреп кенә калмый, аны тәмамлаучылар мәктәпләрдә башлангыч классларда эшли алалар, Татарстан, Россия, Европа, Америка югары белем бирү учрежденияләренә укырга керү өчен дә зур әзерлек белән чыгалар. Дәрестләр, башлыча, дөньяда алдынгы университетлар тәҗрибәсен файдаланып Оксфорд университетында тәзелгән.

Лицейда инглиз һәм төрек телләрен өйрәнү һәм камилләштерү өчен әдәбият җитәрлек, практикада ныгыту өчен аудио - видеокассеталар да байтак. Информатика дәресләре персональ компьютерлар артында үтә, алардан дәрестән соң да файдалану мөмкин. Лицейда һәртөрле түгәрәкләр эшли. Укучылар шәһәрдә үткәрелә торган һәртөрле спорт чараларында да катнашалар, фәннәр олимпиадаларыннан да читтә калмыйлар. 1995 - 96 елларда шәһәр олимпиадаларында дүрт фән буенча беренче урыннарны алдылар, ә 10 нчы сыйныфлар арасында математика фәненнән республикада беренче, Россиядә өченче урынны яуладылар.

Беренче уку елыннан соң ук малайларыбыз инглиз телендә иркен сөйләшәләр, шуңа да тәрҗемәче булып эшләргә мөмкинлекләре туа. Аларны еш кына чит ил фирмалары белән очрашуларга, сөйләшүләргә чакыралар. Елга 4 тапкыр төрле илләрдәге төрек лицейларында үткәрелә торган бәтендәнья тест - олимпиадаларында катнашалар. Безнең лицейны тәмамлаучылар ирекле рәвештә дүрт - инглиз, татар, төрек, рус телләрендә сөйләшәләр.

- Читтән килеп белем алучыларның яшәү шартлары кайгыртыламы соң?

- Һичшиксез. Безнең лицей интернат тибында. Укучылар белән бергә анда тәрбиячеләр, укытучылар да яши, шуңа күрә алар укучыларга теләсә кайсы вакытта ярдәм күрсәтә алалар. Бергәләп дәресләргә әзерләнәләр, ә чәй артында группаларга бүленеп инглиз һәм төрек телләрендә практик белемнәрен арттыралар. Лицейчылар өчен көненә 4 тапкыр кайнар аш әзерләнә. Ял көннәрендә конкурслар, очрашу кичәләре үткәрелә, таэквандо, теннис, баскетбол секцияләре эшли. Яхшы укучылар ел саен җәйге каникул вакытында Төркиягә ял итәргә баралар.

Без хәзер киләсе уку елына укучылар җыябыз. Әгәр дә Норлатта укырга керергә теләүчеләр 30 - 35 кә җыелса, монда килеп имтихан алырга мөмкинлегебез бар. Белешмәләр өчен район мәгариф бүлегенә яки безгә, Түбән Кама шәһәре, Химиклар проспекты 47/35 адресы, (8 (8555) 31 - 76 - 59 телефоны буенча мөрәҗәгать итә аласыз. Татар - төрек лицеена рәхим итегез.

Әңгәмәдәш Ф.ЗЫЯТДИНОВА.

Караклыкның чиге булырмы?

Урлау киң таралган хокук бозулар рәтенә керә. Зур икътисадый зыян китерә торган бу ямьсез күренеш төзелештә, азык - төлек промышленностенда, крестьян хуҗалыклары ассоциацияләрендә еш очрый. Шундый урлауларны кисәтү ведомстводан тыш сак органнарының төп бурычы булып тора. 1996 елда сак бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан агропромышленность комплексы объектларында 150 вак урлау факты ачылып, урлаучылардан 2 миллион 55 мең сумлык матди байлык алынды. 1 миллион 300 мең сум зыян булдырмый калынды. Ит комбинаты, «Сөлчә», Кузнецов исемендәге КХАлар, элеватор, икмәк заводы вак урлаучылар һөҗүменә дучар ителәләр.

Караклыкны кисәтү эше бигрәк тә предприятие администрациясе һәм җәмәгатьчелекнең моңа мөнәсәбәтенә бәйле. Үз вазифаларына кагылышлы рәвештә алар бу очракларга каршы көрәш алып барырга тиешләр. Иң элек матди җаваплы хезмәткәрләрне сайлауда хаталанмаулары мөһим, финанс - хуҗалык исәбен дәрес алып барырга, сак бүлеге хезмәткәрләренә пропуск режимын булдыруда, төрле тикшерүләр үткәрү, хокукый пропаганда алып бару һәм үз вакытында бурларга каршы чара күрүдә ярдәм итәргә тиешләр.

Караклыкка каршы көрәштә хезмәт коллективларының продукция җитештерү, саклау һәм сату буенча матди кызыксынучанлыгын үстерү дә мөһим шарт булып тора. Ведомстводан тыш сак бүлеге этапларга бүленгән «Заслон» операциясе үткәрә. Мартның 3нән 26 сына кадәр дәвам иткән беренче этапта «Төрнәс», «Сөлчә» КХАларында, сөт - май һәм икмәк заводларында 15 вак угры тотылды. Яңа җинаятьләр кодексының 158 нче маддәсе нигезендә урлау, ягъни яшертен рәвештә чит кеше мөлкәтенә кул сузган өчен 200дән алып 700гә кадәр минималь хезмәт хакы күләмендә яки хөкем ителүченең 2 - 7 айлык хезмәт хакы күләмендә штраф алына. Шулай ук 1 - 2 елга төзәтү эшләренә хөкем итү яки 4 - 6 айга һәм 3 елга ирегеннән мәхрүм ителү дә мөмкин. Инде уйлап карагыз, аркылыятканны алып китәргәме, юкмы?..

А.ЛОГИНОВ, ведомстводан тыш сак бүлегенең өлкән инспекторы.

«ТЕАТР ҺӘМ БАЛАЛАР» АТНАЛЫГЫ

Балаларның язгы каникуллары вакытында балалар - яшүсмерләр үзәгендә зур җанлылык хөкем сөрде. Аның театр атналыгына туры килүе балаларның укудан буш вакытын тагын да нәтиҗәлерәк, күнеллерәк итеп үткәрергә мөмкинлек бирде. «Ящь иҗатчы» конкурсы үткәрелгән көнне актлар залында үзләрен сынап карарга теләгән күпсанлы шәһәр һәм авыл мәктәпләре укучыларыннан тыш, бәйгене тамаша кылу өчен бирегә килүчеләр дә байтак булды. Конкурсантлар үз иҗат жимешләрен тәкъдим иттеләр аларга: тәүге шигырьләрен укыдылар, ясаган альбомнарын күрсәттеләр.

Икенче көнне дә үзәк балаларның шат авазларыннан гөрләп торды. Бу көнне сәхнәдә шәһәр һәм авыл мәктәпләре драма коллективлары чыгыш ясады. Ә жюри шәһәрнең беренче мәктәбе үзешчәннәренең Бөек Ватан сугышы елларында эзтабарлар ролен бәяләүгә багышланган һәм шәһәрнең дүртенче урта мәктәбе иҗатчыларының мәктәп тормышыннан алынган спектакльләренә урын бүлеп тәмам аптырады һәм озак баш ватканнан соң ике коллективка да беренче урын бирелде. Тамашачылар урта Камышлы яшь үзешчәннәре чыгышын да жылы кабул итеп, югары бәяләделәр.

Курчак театрлары конкурсында барлыгы 5 коллектив катнашты. Беренчелек зур өстенлек белән балалар - яшүсмерләр үзәге каршында уңышлы эшләп килүче курчак театры коллективына бирелде. Сүз уңаенда шуны да әйтәсе килә, ДЮЦның курчак театры осталары менә инде берничә ел дәвамында шәһәрнең барлык мәктәпкәчә учреждениеләрендә дә көтеп алынган кунаклар. Соңгы елларда шәһәрнең өченче мәктәбендә дә балалар курчак театры нәтиҗәле эшли башлады.

Фольклор. Театр атналыгының бер көне багышланды аңа. Бу көнне үзәкнең актлар залын төрле милли киемнәр киенгән укучылар «басып» алды: тамашачылар төрле милләт халыклары йолаларын зур кызыксыну белән карадылар. Шәһәрнең өченче мәктәбе фольклор коллективының чыгышы иң уңышлысы дип табылуына беркем дә гаҗәпләнмәде: мәктәптә районыбызның төрле төбәкләрендә яшәүче халыкларның традицияләрен, йолаларын өйрәнү буенча эзлекле эш алып барыла. Мәктәпнең фольклор коллективы районда үткәрелгән бер генә шундый чарадан да читтә калмый, алар беренчелекне дә беркемгә дә бирмиләр.

Атналык кысаларында өлкән класс укучылары өчен «Күнелле стартлар» чарасы да үткәрелде.

Р.МИНАПОВА.

Белдерүләр

Сатабыз яки алмаштырабыз

Восточный микрорайонында 10 х 8 метрлы нигез салынган җир участогы (бурасы бар). Фатирга алмашу мөмкинлеге дә бар. Адрес: Совет. ур., 189 - 151.

***

Ике бүлмәле фатир сатыла яки өстәмә түләп бер бүлмәлегә алмаштырыла. Тел.: 5 - 16 - 47 (көндезге 12дән кичке 6га кадәр).

Күрүче юкмы?

Аклы - каралы, 9 - 10 айлык «Лада» кушаматлы овчарканың кайдалыгын белүче булса, бүләк бәрабәренә хәбәр итүен сорыйбыз. Тел.: 2 - 22 - 29.

***

Андрей Евгеньевич Калуков исеменә шофер таныклыгы һәм УАЗ - 3962 автомобиленә документлар белән ирләр сумкасын бүләк бәрабәренә кайтарып бирүне сорыйбыз. Адрес: Маяковский ур., 34

Белдерүләр

Сатабыз

Ашыгыч төстә шикәрчеләр поселогында бөтен уңайлыклары булган 1 бүлмәле фатир. Югары Норлатта Зиннур Төхвәтуллинга мөрәҗәгать итәргә.

***

Шәхси йорт. Адрес: Маяковский ур., 1.

***

Колхоз базары янындаике бүлмәле фатир. Тел.: 2 - 28 - 21.

***

«Алмалык»ка якын гына җирдә 6 сутыйлы дача участогы (җиләк - җимеш куаклары утыртылган). Тел.: 5 - 18 - 53.

***

«Москвич - 412» һәм «Урал» мотоциклы. Тел.: 2 - 18 - 45.

***

«Москвич - 412»не запас частьларга. Адрес: Октябрьская ур., 60 - 11, тел.: 2 - 10 - 60 (кичке 6дан соң).

***

Мунча бурасы. Адрес: Декабристлар ур., 12, тел.: 2 - 17 - 75 (кичке 5тән соң).

***

Койма тоту өчен тимер челтәр. Адрес: Школьная ур. 14 - 9.

***

Сатуда 2 һәм 3 бүлемле «Стинол» суыткычлары һәм туңдыргычлары бар. Бәяләре кешечә, гарантия бар, өегезгә китереп биреп була. Лицензиябез сер. А - 96 № 104251. Тел.: 2 - 11 - 24, 5 - 19 - 95.

НГДУның бина һәм корылмаларны капиталь ремонтлау цехы (ЦКРЗиС) теплицасында (битум заводы янында) сатуда тере чәчәкләр бар.

Администрация.

Сатып алабыз

Бакыр, җиз, бронза, мотор һәм электр алюминие калдыклары кабул итәбез. Тел.: 2 - 18 - 76.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, җомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, жаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә.